


# ИДЕЛ БУЕ ХАЛЫКЛАРЫ МИФОЛОГИЯСЕ



# МИФОЛОГИЯ НАРОДОВ ПОВОЛЖЬЯ

УДК 2-264
ББК 82.3(2Рос=Тат)
И28

*Александр Бакулевский, Екатерина Васильева, Айгөл Ишбердина, Мария Клюкина, Василий Мустаев, Фәридә Ризаева, Алсу Тимергалина, Юлия Щетинкина* рәсемнәре.

Иллюстрации *Александра Бакулевского, Екатерины Васильевой, Айгуль Ишбердиной, Марии Клюкиной, Василия Мустаева, Фариды Ризаевой, Алсу Тимергалиной, Юлии Щетинкиной.*

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүенең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

**Идел буе халыклары мифологиясе = Мифология народов Поволжья** /
И28 [төз. А. Галиәхмәтова]. — Казан : Татар. кит. нәшр., 2019 . — 95 б.
ISBN 978-5-298-03932-1

Кешеләр дөнья яратылганнан алып аның хакында үз күзаллауларын булдырганнар. Дөньяның барлыкка килүе, тирә-юньдәге ак һәм кара көчләр турында үз тарихларын уйлап чыгарганнар, аларны буыннан-буынга тапшырып барганнар. Бу китаптагы мифлар, легендалар һәм әкиятләр — бик борынгы бабаларыбыз ышануларының нәни генә бер өлеше.

Как возникла Вселенная? Как появилась жизнь на Земле? Человек издавна стремился познать мир. До нас дошли многочисленные сказания и мифы различных народов Поволжья о сотворении мира, о природе и её законах, о добре и зле, о смысле и причинах происходящих событий. В эту книгу вошла лишь малая часть мифов, легенд и сказок наших далёких предков.

УДК 2-264
ББК 82.3(2Рос=Тат)

ISBN 978-5-298-03932-1

© Татарстан китап нәшрияты, 2019
© Галиәхмәтова А. Ф., төз.,
татарчага тәрҗемә, 2019

## ЭЧТӘЛЕК


Ай белән Урал тауларының барлыкка килүе . . . . . . . . . . 5
Агыйдел белән Җаек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Тереташ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Водэж һәм су алиһәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Волга-Рав һәм Каспий . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Виряня . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Волколак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
Велес Перунның терлекләрен урлый . . . . . . . . . . . . . 49
Су анасы белән ятимә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Шүрәлене ничек алдарга? . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60
Җир ничек барлыкка килгән? . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
Вожо-кәләш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
Кирәмәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79
Азамат күпере . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
Сүзлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88

## СОДЕРЖАНИЕ

Как возникли Луна и Уральские горы? (перевод Ч. Ялаловой) 7
Агидель и Яик (перевод Ч. Ялаловой) . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Живой камень (перевод Ч. Ялаловой) . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Водэж и богиня воды (переложение А. Иликаева) . . . . . . . . . 23
Волга-Рав и Каспий (перевод Ч. Ялаловой) . . . . . . . . . . . . 31
Виряня (перевод Ч. Ялаловой) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
Волколак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
Велес похищает скот Перуна . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
Водяная и сирота (перевод Ч. Ялаловой) . . . . . . . . . . . . . 56
Как обмануть Шурале? (перевод Н. Ишмухаметова) . . . . . . . . 63
Как землю сотворили? (перевод Ч. Ялаловой) . . . . . . . . . . . 67
Невеста-вожо (перевод Н. Кралиной) . . . . . . . . . . . . . . . . 74
Киреметь (перевод Ч. Ялаловой) . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
Мост Азамата (перевод Ч. Ялаловой) . . . . . . . . . . . . . . . . 87
Словарь . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91



# АЙ БЕЛӘН УРАЛ ТАУЛАРЫНЫҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ

Борын-борын заманда күктә ике кояш булган. Бу ике кояш бер ялсыз яктырткан да яктырткан. Кешеләр бик изаланган моңа. Көн яктысында йоклый алмаган бер бай:

— Кем дә кем шушы ике кояшның берсен атып төшерә, шуңа кызымны бирәм, ярты байлыгымны бирәм, — дигән.

Ат җиткән җиргә ат җибәргән, хат җиткән җиргә — хат, байның сүзен ишетмәгән кеше калмаган, төрле җирләрдән укчы мәргәннәр җыела башлаган. Күпләр атып, үзләрен сынап караганнар, тик кояшларның берсенә дә тидерә алмаганнар.

— Мәргән булып йөрүегез корсын, — дип, уңмаган укчыларны борып кайтара торган бай.

Иң соңыннан гына Урал батыр килгән, ди. Мөгез җәясен алып, тарамыш керешен тартып, алмас угын салып, колач киереп атып җибәргән. Таулар ишелеп төшкән. Аккан сулар туктап калган. Ук кояшларның берсенә барып та тигән, аны кыл урталай ярып узып та киткән.

— Ай!

— Ай! — дип кычкырган җәйләү халкы.

Ярык кояшның яртысы күктә калган, ә икенче яртысы җиргә егылып төшкән дә хәзинәгә бай зур тауга әверелгән, ди. Ярылгач,



бу кояшның нуры беткән. Шул көннән башлап кешеләр төнлә йоклап ял итәргә, көндез кояш яктысында эшләр өчен көч тупларга гадәтләнгәннәр.

Ук тигәндә «ай» дип кычкырганга күрә, күктәге ярылган кояшка да ай исеме ябышып калган. Ә тауны әлеге егет хөрмәтенә «Урал тавы» дип йөртә башлаганнар.

## КАК ВОЗНИКЛИ ЛУНА И УРАЛЬСКИЕ ГОРЫ?

Давным-давно на небе было два солнца. Они без устали, без передыху освещали землю. И люди сильно страдали от этого. Один бай порядком измучился — никак не уснуть при свете — и сказал: «Кто сможет сбить выстрелом одно из двух солнц, получит в жёны мою дочь, а также дам ему половину своего богатства».

Весть эту разнесли повсюду, куда могли дойти письма и доскакать лошади. Не осталось в стране никого, кто не был извещён о решении бая.

И стали прибывать самые меткие стрелки — мэргэны. Многие из них пустили свои стрелы в небеса, но не смогли нанести солнцам никакого вреда.

И каждого незадачливого стрелка бай отправлял восвояси со словами: «Вам только по воробьям стрелять!»

Одним из последних приехал батыр по имени Урал. Взял он

свой лук, сделанный из рога, вставил в тетиву из просмоленных жил алмазную стрелу, натянул на размах руки и выстрелил — всё вокруг зазвенело да загудело. От звука того обрушились горы и застыли реки. А алмазная стрела взмыла вверх и угодила прямо в одно из солнц, пробила его насквозь, развалила на две части и полетела дальше. «Ай! Ай!» — только и вскрикнул весь народ на кочёвке бая.

Одна половина солнца осталась на небе, другая упала на землю и превратилась в огромную гору, полную сокровищ. Расколовшись надвое, солнце потеряло свой блеск. После этого люди стали по ночам, в темноте, спать, а днём, под лучами солнца, трудиться. Так как люди на земле при виде расколотого солнца закричали «Ай!», одну часть солнца стали называть «ай». Гору, что образовалась из второй его половины, в честь егета-мэргэна назвали «Уралтау».

## АГЫЙДЕЛ БЕЛӘН ҖАЕК

Җаек, Сакмар, Агыйдел, Караидел, Нөгеш, Олы Иек, Кече Иек — барысы да бер яктан чыкканнар. Борын заманда алар сөйләшә дә белгәннәр, ди. Болай дип сүз куешкан болар: «Барыбыз да бер якка агып барыйк. Кояшка таба агып китсәк, берәр җирдә тагын кушылырбыз». Шулай итеп, Урал буйлап киткәннәр.

Җаек беренче булып ашыкмый гына кузгалган. Алдында каршылыклар очрамагач, үзенә юлны да бик җиңел генә салган.

Иек белән Сакмарларның юлларында аркылы яткан таулар очраган. Бормалана-бормалана, алар да тигезлеккә килеп чыкканнар. Шуннан бергә килеп кушылганнар.

Агыйдел белән Караиделнең юлында текә-текә таулар, ташлар күп булганга, алар, урау юллар үтеп, арткарак калганнар. Артта калгач, Агыйдел дусларына кычкыра ди:

— Һәәй, сез кайсы якка киттегез?

Иек белән Сакмар җавап бирмәкче булганнар икән, Җаек аларны тыйган.

— Дәшмәгез, җавап бирмәгез, барсын үз юлы белән генә, безгә кушылмасын.

Агыйделгә тау-таш арасында бик күп инешләр кушылган. Шуңа күрә аның суы да күбәйгән, көче дә арткан. Җаек шуннан курыккан булган да инде. Бу мактаныр, үз исемен тагар дип шикләнгән ул.

Агыйдел һаман киткән. Җавап ишетелмәгәч, ул Көнгәк янында икенче якка борылган. Юл уңаена башка елгаларны да үзенә кушып барган. Бара торгач, Караиделне юлдаш итеп алып, Камага барып җиткән. Соңрак тагын да көчлерәк Иделгә кушылып, Каспийга ук барып тоташкан.

Шуннан карасалар, Идел бик зур икән, ә Җаек бәләкәй генә.

Шулай итеп, көнләшүе аркасында Җаек сай сулы булып калган. Аның суында кораблар да йөри алмаган. Ә Агыйделдә,